**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

02.04. 2019 ел Чирмешән авылы №126

# КАРАР

**Территорияне планлаштыру проектын**
**һәм межалау проектын эшли**
**башлау турында**

"ГеоКомплекс - М" ЖЧЖ 26. 03.2019 №74 язма мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң, РФ, Шәһәр төзелеше кодексының 46, 51 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә урнашкан объект территориясен планлаштыру проектын һәм межалау проектын эшли башлау турында **КАРАР БИРӘМ:**

1. “ГеоКомплекс - М" ЖЧЖ Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә урнашкан "ТатРИТЭКнефть " СП № 71760, 1720, 1780, 1729 Кыязлы нефть ятмаларын төзекләндерү" объекты территориясен планлаштыру проектын һәм межалау проектын эшләүгә керешергә рөхсәт итәргә.

2. Документларны эшләп бетергәннән соң, барлык кызыксынган оешмалар белән билгеләнгән тәртиптә планлаштыру проектын килештерергә һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә тәкъдим итәргә кирәк.

3. Әлеге карарны хокукый порталда (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И. Н. Шәйдуллин